КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 11 сентябрь г.Казань № 817

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 28 декабрь, 1078 нче, 2014 ел, 22 февраль, 109 нчы; 2014 ел, 24 февраль, 118 нче; 2014 ел, 30 апрель, 284 нче; 2014 ел, 2 июнь, 374 нче; 2014 ел, 17 июнь, 418 нче; 2014 ел, 8 июль, 473 нче; 2014 ел, 9 июль, 477 нче; 2014 ел, 25 август, 612 нче; 2014 ел, 1 октябрь, 709 нчы; 2014 ел, 24 ноябрь, 901 нче; 2014 ел, 6 декабрь, 956 нчы; 2014 ел, 31 декабрь, 1083 нче; 2015 ел, 1 июнь, 390 нчы; 2015 ел, 24 июнь, 459 нчы; 2015 ел, 25 июнь, 460 нчы; 2015 ел, 28 июль, 549 нчы; 2015 ел, 16 октябрь, 770 нче; 2015 ел, 30 ноябрь, 906 нчы; 2015 ел, 28 декабрь, 992 нче; 2016 ел, 31 март, 190 нчы; 2016 ел, 30 апрель, 268 нче; 2016 ел, 16 декабрь, 940 нчы; 2017 ел, 9 февраль, 73 нче; 2017 ел, 23 июнь, 423 нче; 2017 ел, 13 июль, 480 нче; 2017 ел, 21 октябрь, 802 нче; 2017 ел, 15 декабрь, 1002 нче; 2018 ел, 27 июнь, 533 нче; 2018 ел, 20 декабрь, 1192 нче; 2019 ел, 11 февраль, 94 нче; 2019 ел, 11 март, 167 нче; 2019 ел, 28 март, 229 нчы; 2019 ел, 3 июнь, 465 нче; 2019 ел, 19 июль, 600 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә

алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «2014 – 2021 елларга» сүзләрен «2014 – 2024 елларга» сүзләренә алыштырырга;

1 нче пунктта «2014 – 2021 елларга» сүзләрен «2014 – 2024 елларга» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасында (алга таба – Программа):

исемендә «2014 – 2021 елларга» сүзләрен «2014 – 2024 елларга» сүзләренә алыштырырга;

Программа паспортында:

«Программа исеме» юлында «2014 – 2021 елларга» сүзләрен «2014 – 2024 елларга» сүзләренә алыштырырга;

«Программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2014 – 2024 еллар:<br>I этап: 2014 – 2016 еллар;<br>II этап: 2017 – 2024 еллар»; |

«Ярдәмче программалар исемлеге» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программалар исемлеге | 1. 2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасында дәүләт икътисадый сәясәтен камилләштерү.<br>2. 2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү.<br>3. 2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасында социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтү.<br>4. 2015 – 2024 елларга Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру.<br>5. 2015 – 2021 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү.<br>6. 2016 – 2021 елларга Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерү.<br>7. 2018 – 2024 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү.<br>8. 2017 – 2024 елларга Татарстан Республикасы территориясендә индустриаль (сәнәгать) парклар һәм сәнәгать мәйданчыклары төзү һәм үстерү.<br>9. «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасына бюджет инвестицияләре һәм аны капиталь ремонтлау»; |

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | Программаны финанслауның гомуми күләме 56 182 987,318 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 48 285 357,808 мең сум, җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 7 176 361,06 мең сум, җәлеп итәргә планлаштырыла торган җирле бюджетлар акчасы исәбеннән – 8 618,87 мең сум һәм җәлеп итәргә планлаштырыла торган бюджеттан тыш чыганаклар акчасы исәбеннән – 712 649,58 мең сум. |

| Ел | Акча күләме, мең сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | барлыгы | Татарстан Республикасы бюджеты | җәлеп ителергә планлаштырылган акча | | |
| | | | федераль бюджеттан | җирле бюд-жеттан | бюджеттан тыш чыганаклардан |
| 2014 | 3 669 180,12 | 1 794 954,55 | 1 717 775,57** | 100,0 | 156 350,0 |
| 2015 | 3 778 805,15 | 1 908 009,45 | 1 701 821,12*** | 150,0 | 168 824,58 |
| 2016 | 3 202 255,21 | 2 457 901,0 | 596 181,71**** | 472,5 | 147 700,0 |
| 2017 | 4 426 149,442 | 4 120 124,882 | 248 450,26* | 1 499,3 | 56 075,0 |
| 2018 | 5 805 452,27 | 5 700 969,9***** | 71 405,8* | 1901,57 | 31 175,0 |
| 2019 | 12 763 645,985 | 11 664 123,185****** | 1 066 019,8* | 1 328,0 | 32 175,0 |
| 2020 | 6 088 929,66 | 5 694 980,5 | 360 026,6* | 747,5 | 33 175,0 |
| 2021 | 5 996 050,4 | 5 748 795,5 | 213 474,9* | 605,0 | 33 175,0 |
| 2022 | 5 380 065,9 | 4 919 256,0 | 442 204,9 | 605,0 | 18 000,0 |
| 2023 | 2 679 082,2 | 2 138 121,4 | 522 355,8 | 605,0 | 18 000,0 |
| 2024 | 2 393 371,0 | 3 128 121,4 | 236 644,6 | 605,0 | 18 000,0 |
| Барлыгы | 56 182 897,318 | 48 285 357,808 | 7 176 361,06 | 8 618,87 | 712 649,58 |

Искәрмә: Финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш.

*Программаны федераль бюджет акчасы исәбеннән ресурслар белән тәэмин итү күләме федераль бюджеттан бюджетларына субсидия бирелә торган Россия Федерациясе субъектларын конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча ел саен билгеләнәчәк.

**Шул исәптән 193 209,83529 мең сумы – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 30 декабрь, 1151 нче карары белән расланган 2011 – 2013 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча республика программасы чараларын тормышка ашыру өчен 2012 – 2013 елларда алынган федераль субсидияләр акчасының үзләштерелми калган, 2014 елда үзләштерелгән өлеше.

***Шул исәптән 437 206,63906 мең сумы – «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру өчен

| | |
|---|---|
| | 2014 елда алынган федераль субсидияләр акчасының үзләштерелми калган, 2015 елда үзләштерелгән өлеше.<br>****Шул исәптән 1 364,34855 мең сумы – «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру өчен 2015 елда алынган федераль субсидияләр акчасының үзләштерелми калган, 2016 елда үзләштерелгән өлеше.<br>*****Шул исәптән 11 328,6 мең сумы – «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында дәүләт икътисадый сәясәтен камилләштерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру өчен 2017 елда алынган акчаның үзләштерелми калган, 2018 елда үзләштерелгән өлеше.<br>******Шул исәптән 18 432,0 мең сумы – «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында дәүләт икътисадый сәясәтен камилләштерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру өчен 2018 елда алынган акчаның үзләштерелми калган һәм 111 649,62509 мең сумы – «2018 – 2021 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру өчен 2018 елда алынган акчаның үзләштерелми калган, 2019 елда үзләштерергә планлаштырыла торган өлеше;» |

«Еллар буенча бүлеп, Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүлеп, Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программа чараларын тулы күләмдә тормышка ашыру түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>тулаем төбәк продукт күләмен (алга таба – ТТП) 2013 ел дәрәҗәсенә чагыштырма бәяләрдә 2024 елда 22,7 процентка арттыру;<br>Татарстан Республикасының бер кешесенә 2024 елга туры чит ил инвестицияләре күләмен 125 АКШ долларына кадәр арттыру;<br>2017 елга эш белән тәэмин ителгән халыкның гомуми санында микропредприятиеләрдә, кече һәм урта предприятиеләрдә һәм шәхси эшмәкәрләрдә эш белән тәэмин ителгән хезмәткәрләрнең уртача исемлеге (тышкы ике урында эшләүдән тыш) саны өлешен 26,9 процентка кадәр арттыру;<br>2024 елга кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары санын (индивидуаль эшмәкәрләрне кертеп) 1 мең кешегә исәпләгәндә 44 берәмлеккә кадәр арттыру;<br>сәнәгать җитештерүенең гомуми күләмендә инновацион продукция өлешен 20,5 процентка кадәр арттыру; |

| | |
|---|---|
| | тикшерелгән оешмаларның гомуми санында технологик инновацияләрне гамәлгә ашыручы оешмаларның чагыштырма авырлыгын 18,5 процентка кадәр арттыру;<br>Татарстан Республикасы гариза бирүчеләренең дәүләт хезмзтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатыннан канәгать булу дәрәҗәсен 2021 елга 90 процентка кадәр арттыру;<br>тору урыны буенча «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрдән файдалану мөмкинлеге булган гражданнар өлешен (шул исәптән дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә) 2021 елга 90 процентка кадәр арттыру;<br>урнаштырылган сатып алуларның гомуми санында электрон формада ачык аукционнар өлешен 85 процент дәрәҗәсендә саклап калу;<br>көндәшлекле сатып алулар өлешен (торгларның гомуми санына карата бердән күбрәк катнашучылар саны) 74,54 процентка кадәр арттыру;<br>кабул ителгән тариф карарларын исәпкә алып, коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртү индексы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре өчен билгеләнгән иң чик (максималь) индексларга туры килә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре өлешен 100 процент дәрәҗәсендә саклап калу;<br>барлык авыл җирлекләрендә генераль планнар эшләү;<br>Татарстан Республикасы территориаль планлаштыру схемасына ел саен төзәтмәләр кертү;<br>вакытында бирелгән мәгълүмат материалларының өлешен аларның гомуми саныннан 100 процент дәрәҗәсендә саклап калу;<br>Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитетында коррупциягә каршы сәясәт чараларын тормышка ашыру буенча расланган программалар (планнар) белән каралган һәм башкарылган чаралар өлешен 100 процент дәрәҗәсендә саклап калу;<br>төзелгән контрактларның гомуми кыйммәтендә сатып алуларның башкарылмаган конкурентлы ысуллары нәтиҗәләре буенча төзелгән контрактлар кыйммәте өлешен 9 процент дәрәҗәсендә саклап калу;<br>ярдәм күрсәтелгән социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар санын кимендә 200 берәмлеккә арттыру;<br>Татарстан Республикасы икътисадының чимал булмаган база тармакларына караган эре һәм урта предприятиеләрдә хезмәт җитештерүчәнлеген тотрыклы үстерү;<br>Программада катнашучы предприятиеләрдә эш урыннарының гомуми санында югары җитештерүчәнлекле эш урыннары өле- |

| | |
|---|---|
| | шен 2024 ел ахырына 2016 ел күрсәткеченә карата 1,2 тапкырга арттыру;<br>Кластерда катнашучы оешмаларның бер хезмәткәренә эшләп чыгаруны 2021 елга кыйммәти чагылышта 6 процентка арттыру;<br>фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсендә ике һәм аннан да күбрәк Кластерда катнашучы оешмалар тарафыннан бергәләп яки ике һәм аннан да күбрәк Кластерда катнашучы оешмаларның чит ил оешмалары белән бергәләп башкарыла торган эшләр һәм проектлар күләмен ел саен 5 процентка кадәр арттыру;<br>кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары әйләнешен 2014 ел күрсәткеченә карата даими бәяләрдә 129,3 процентка кадәр арттыру;<br>кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты әйләнешен бер хезмәткәргә исәпләгәндә 2014 елгы күрсәткечкә карата даими бәяләрдә 120,1 процентка кадәр арттыру;<br>кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары (индивидуаль эшмәкәрләрдән тыш) әйләнешендә эшкәртү сәнәгате өлешен 17 процентка кадәр арттыру;<br>Татарстан Республикасы экспортының гомуми күләмендә кече һәм урта предприятиеләр экспорты өлешен 7,4 процентка кадәр арттыру;<br>федераль бюджет акчасы исәбеннән кече һәм урта эшмәкәрлеккә дәүләт ярдәме күрсәтүне финанслар белән тәэмин итүнең гомуми күләмендә монопрофильле муниципаль берәмлекләрдә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өлкәсендәге чараларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән акча өлешен 10 процентка кадәр арттыру;<br>сатып алулар нәтиҗәләре буенча төзелгән шартнамәләрнең җыелма кыйммәти күләмендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларында юридик затларның аерым төрләре белән гамәлгә ашырыла торган товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуларның гомуми күләмен 25 процентка кадәр, шул исәптән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары гына катнашкан кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары белән сатып алулар нәтиҗәләре буенча төзелгән шартнамәләрнең еллык кыйммәти күләмендә 15 процентка кадәр арттыру;<br>төбәк проекты кысаларында ярдәм күрсәтелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары һәм үзмәшгуль гражданнар санын 15,9 мең берәмлеккә кадәр арттыру (арта бара торган нәтиҗә белән);<br>бизнес алып бару нигезләрен, финанс грамоталылыгы һәм эшмәкәрлек эшчәнлегенең башка күнекмәләрен өйрәнгәннәрнең санын 11,1 меңгә кадәр арттыру»; |

II бүлектә:

уникенче – егерменче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасында дәүләт икътисадый сәясәтен камилләштерү»;

2) «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү»;

3) «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасында социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтү»;

4) «2015 – 2024 елларга Татарстан Республикасы предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру»;

5) «2015 – 2021 елларга Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерын үстерү»;

6) «2016 – 2021 елларга Татарстан Республикасында интеллектуаль милек базарын үстерү»;

7) «2018 – 2024 елларга Татарстан Республикасының кече һәм урта эшмәкәрлеген үстерү»;

8) «2017 – 2024 елларга Татарстан Республикасы территориясендә индустриаль (сәнәгать) парклар һәм сәнәгать мәйданчыклары төзү һәм үстерү»;

9) «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү».»;

егерме өченче – утызынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бюджет акчасын исәпкә алмыйча, төп капиталга инвестицияләр күләме 100 процентка кадәр арту;

2024 елга Татарстан Республикасының бер кешесенә исәпләгәндә туры чит ил инвестицияләре күләмен 125 АКШ долларына кадәр арттыру;

Татарстан Республикасында башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү сыйфатын югары дәрәҗәдә тәэмин итү;

Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек нәтиҗәле эшләсен һәм үссен өчен шартларны яхшырту: инвестицион һәм эшмәкәрлек рискларын киметү, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен финанс ресурсларыннан файдалану мөмкинлеген арттыру, продукцияне төбәк һәм чит ил базарларына чыгару өчен тышкы икътисадый элемтәләрне үстерү;

ярдәм күрсәтелгән социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар санын кимендә 200 берәмлеккә кадәр арттыру;

Татарстан Республикасы икътисадының чимал булмаган база тармакларына караган эре һәм урта предприятиеләрендә хезмәт җитештерүчәнлеге арту;

Кластерда катнашучы оешмаларның бер хезмәткәренә 2021 елга эшләп чыгаруны кыйммәти чагылышта 6 процентка арттыру;

фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсендә ике һәм ан-нан да күбрәк Кластерда катнашучы оешмалар тарафыннан бергәләп яки ике һәм аннан да күбрәк Кластерда катнашучы оешмаларның чит ил оешмалары белән бергәләп башкарыла торган эшләр һәм проектлар күләмен ел саен 5 процентка кадәр арттыру.»;

илле дүртенче – илле алтынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаны тормышка ашыруның гомуми вакыты: 2014 – 2024 еллар.

I этап: 2014 – 2016 еллар;

II этап: 2017 – 2024 еллар.»;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

### «III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаны финанслауның гомуми күләме 56 182 987,318 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 48 285 357,808 мең сум, җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы исәбеннән – 7 176 361,06 мең сум, җәлеп итәргә планлаштырыла торган җирле бюджетлар акчасы исәбеннән – 8 618,87 мең сум һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы исәбеннән – 712 649,58 мең сум.

| Ел | Акча күләме, мең сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | барлыгы | Татарстан Республикасы бюдже-ты | җәлеп ителергә планлаштырылган акча | | |
| | | | федераль бюджеттан | җирле бюд-жеттан | бюджеттан тыш чыганаклардан |
| 2014 | 3 669 180,12 | 1 794 954,55 | 1 717 775,57** | 100,0 | 156 350,0 |
| 2015 | 3 778 805,15 | 1 908 009,45 | 1 701 821,12*** | 150,0 | 168 824,58 |
| 2016 | 3 202 255,21 | 2 457 901,0 | 596 181,71**** | 472,5 | 147 700,0 |
| 2017 | 4 426 149,442 | 4 120 124,882 | 248 450,26* | 1 499,3 | 56 075,0 |
| 2018 | 5 805 452,27 | 5 700 969,9***** | 71 405,8* | 1901,57 | 31 175,0 |
| 2019 | 12 763 645,985 | 11 664 123,185****** | 1 066 019,8* | 1 328,0 | 32 175,0 |
| 2020 | 6 088 929,66 | 5 694 980,5 | 360 026,6* | 747,5 | 33 175,0 |
| 2021 | 5 996 050,4 | 5 748 795,5 | 213 474,9* | 605,0 | 33 175,0 |
| 2022 | 5 380 065,9 | 4 919 256,0 | 442 204,9 | 605,0 | 18 000,0 |
| 2023 | 2 679 082,2 | 2 138 121,4 | 522 355,8 | 605,0 | 18 000,0 |
| 2024 | 2 393 371,0 | 3 128 121,4 | 236 644,6 | 605,0 | 18 000,0 |
| Барлыгы | 56 182 897,318 | 48 285 357,808 | 7 176 361,06 | 8 618,87 | 712 649,58 |

Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм, тиешле бюджетлар мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен тәгаенләнергә тиеш.

*Федераль бюджет акчасы исәбеннән Программаны ресурслар белән тәэмин итү күләме федераль бюджеттан бюджетларына субсидияләр бирелә торган Россия Федерациясе субъектларын конкурс нигезендә сайлап алу йомгаклары буенча ел саен билгеләнә.

**Шул исәптән 193 209,83529 мең сумы – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 30 декабрь, 1151 нче карары белән расланган 2011 – 2013 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча республика программасы чараларын тормышка ашыру өчен 2012 – 2013 елларда алынган федераль субсидияләр акчасының үзләштерелми калган, 2014 елда үзләштерелгән өлеше.

***Шул исәптән 437 206,63906 мең сумы – «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру өчен 2014 елда алынган федераль субсидияләр акчасының үзләштерелми калган, 2015 елда үзләштерелгән өлеше.

****Шул исәптән 1 364,34855 мең сумы – «2014 – 2017 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру өчен 2015 елда алынган федераль субсидияләр акчасының үзләштерелми калган, 2016 елда үзләштерелгән өлеше.

*****Шул исәптән 11 328,6 мең сумы – «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында дәүләт икътисадый сәясәтен камилләштерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру өчен 2017 елда алынган акчаның үзләштерелми калган, 2018 елда үзләштерелгән өлеше.

******Шул исәптән 18 432,0 мең сумы – «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында дәүләт икътисадый сәясәтен камилләштерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру өчен 2018 елда алынган акчаның үзләштерелми калган һәм 111 649,62509 мең сумы – «2018 – 2021 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру өчен 2018 елда алынган акчаның үзләштерелми калган, 2019 елда үзләштерергә планлаштырыла торган өлеше;

Программага теркәлгән 1 нче һәм 2 нче кушымталарны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

«2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасында дәүләт икътисадый сәясәтен камилләштерү» ярдәмче программасында (алга таба – 1 нче ярдәмче программа):

исемендә «2014 – 2021 елларга» сүзләрен «2014 – 2024 елларга» сүзләренә алыштырырга;

1 нче ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программаның исеме» юлында «2014 – 2021 елларга» сүзләрен «2014 – 2024 елларга» сүзләренә алыштырырга;

«Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2014 – 2024 еллар»; |

1 нче ярдәмче программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td rowspan="3">«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре</td><td colspan="4">Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 15 415 648,26 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 15 305 411,76 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 110 236,5 мең сум:</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Ел</td><td colspan="3">Акча күләме, мең сум</td></tr>
<tr><td>барысы</td><td>Татарстан Республикасы</td><td>федераль бюджеттан</td></tr>
</table>

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | бюджетыннан | |
| | 2014 | 896 009,75 | 896 009,75 | - |
| | 2015 | 1 249 957,16 | 1 139 720,66 | 110 236,5 |
| | 2016 | 1 722 097,6 | 1 722 097,6 | - |
| | 2017 | 1 687 460,55 | 1 687 460,55 | - |
| | 2018 | 1 947 977,2 | 1 947 977,2* | - |
| | 2019 | 1 905 467,0 | 1 905 467,0** | - |
| | 2020 | 1 708 274,7 | 1 708 274,7 | - |
| | 2021 | 1 697 623,0 | 1 697 623,0 | - |
| | 2022 | 867 683,5 | 867 683,5 | - |
| | 2023 | 866 548,9 | 866 548,9 | - |
| | 2024 | 866 548,9 | 866 548,9 | - |
| | Барлыгы | 15 415 648,26 | 15 305 411,76 | 110 236,5 |
| | *Шул исәптән 11 328,6 мең сумы – Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру өчен 2017 елда алынган акчаның үзләштерелми калган, 2018 елда үзләштерелгән өлеше.<br>**Шул исәптән 18 432,0 мең сумы – Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру өчен 2018 елда алынган акчаның үзләштерелми калган, 2019 елда үзләштерергә планлаштырыла торган өлеше»; | | | |

«Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Ярдәмче программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар буенча бүлеп, Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашы-рудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индика-торлары) һәм Ярдәмче про-грамманың бюджет нәти-җәлелеге күр- | 2024 елга Ярдәмче программаны тормышка ашыру нәтиҗәсендә:<br>2024 елда тулаем төбәк продукты күләме (алга таба – ТТП) 2013 ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 22,7 процентка артачак;<br>2024 елга Татарстан Республикасының бер кешесенә исәпләгәндә туры чит ил инвестицияләре күләме 125 АКШ долларына кадәр артачак;<br>сәнәгать җитештерүенең гомуми күләмендә инновацион продукция өлеше 20,5 процентка кадәр артачак;<br>тикшерелгән оешмаларның гомуми күләмендә технологик инновацияләрне гамәлгә ашыручы оешмаларның чагыштырма авырлыгы 18,5 процентка кадәр артачак;<br>төзелгән контрактларның гомуми кыйммәтендә сатып алуларның башкарылмаган конкурентлы ысуллары нәтиҗәләре буенча төзелгән контрактлар кыйммәте өлеше 9 процент дәрәҗәсендә сакланачак; |

| | |
|---|---|
| сәткечләре | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына беркетелгән сәнәгать предприятиеләренең гомуми санында зарар күреп эшләгән сәнәгать предприятиеләренең өлеше 18,5 процентка кадәр кимиячәк;<br>Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына беркетелгән сәүдә предприятиеләренең гомуми санында зарар күреп эшләгән сәүдә предприятиеләренең өлеше 20,8 процентка кадәр кимиячәк;<br>технологик тоташтыру өчен кирәкле этапларның (процедураларның) иң чик саны 5 дәрәҗәсендә сакланачак;<br>технологик тоташтыруга заявка кергән көннән технологик тоташтыру турындагы актка имза куйган көнгә кадәр куллanучыларны (150 киловаттка кадәр) тоташтыруның иң чик вакыты 31 көнгә кадәр кыскартылачак;<br>сәнәгатьтә уртача айлык хезмәт хакының тулаем алганда Татарстан Республикасы буенча уртача айлык хезмәт хакына карата мөнәсәбәте 114,5 процент тәшкил итәчәк;<br>сәнәгать җитештерүенең гомуми күләмендә эшкәртүче җитештерүләрнең өлеше 72,6 процентка кадәр артачак;<br>Татарстан Республикасы экспортының гомуми күләмендә чимал булмаган продукциянең өлеше 78 процентка кадәр артачак;<br>урнаштырылган сатып алуларның гомуми санында электрон рәвештә үткәрелгән ачык аукционнарның өлеше 85 процент тәшкил итәчәк;<br>заказлар урнаштыруның икътисадый нәтиҗәлелеге (экономия суммасының урнаштырылган заказлар суммасына карата мөнәсәбәте) 4 процент тәшкил итәчәк;<br>кабул ителгән тариф карарларын исәпкә алып, коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртү индексы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре өчен билгеләнгән иң чик (максималь) индексларга туры килә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре өлеше 100 процент дәрәҗәсендә сакланачак;<br>ресурслары база алдындагы чорның җылылык энергиясе тарифларына салынган, инвестицион программаларны үтәмәгән оешмалар санының база чорында инвестицион программаларына төзәтмәләр кертелгән яки чираттагы җайга салу чорына кирәкле тулаем кереме киметелгән оешмалар санына карата мөнәсәбәте 100 процент дәрәҗәсендә сакланачак;<br>муниципаль берәмлекләр территорияләренең ресурс потенциалыннан нәтиҗәле файдалану һәм шәһәрне җайга салуның нәтиҗәле механизмнарын формалаштыру гамәлгә ашырылачак;<br>шәһәр округларында һәм шәһәр җирлекләрендә теркәлгән территориаль иҗтимагый үзидарәләрнең гомуми саныннан |

| | |
|---|---|
| | территориаль иҗтимагый үзидарәләр җитәкчеләренә компенсация түләүләрен гамәлгә ашыруга субсидияләр рәвешендә ярдәм күрсәтелгән территориаль иҗтимагый үзидарәләрнең өлеше ел саен 100 процент тәшкил итәчәк»; |

II бүлекнең «Ярдәмче программаның төп чаралары тасвирнамәсе» бүлекчәсендәге егерменче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакыты: 2014 – 2024 еллар.»;

1 нче ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 15 415 648,26 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 15 305 411,76 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 110 236,5 мең сум.

| Ел | Акча күләме, мең сум | | |
|---|---|---|---|
| | барысы | Татарстан Республикасы бюджетыннан | федераль бюджеттан |
| 2014 | 896 009,75 | 896 009,75 | - |
| 2015 | 1 249 957,16 | 1 139 720,66 | 110 236,5 |
| 2016 | 1 722 097,6 | 1 722 097,6 | - |
| 2017 | 1 687 460,55 | 1 687 460,55 | - |
| 2018 | 1 947 977,2 | 1 947 977,2* | - |
| 2019 | 1 905 467,0 | 1 905 467,0** | - |
| 2020 | 1 708 274,7 | 1 708 274,7 | - |
| 2021 | 1 697 623,0 | 1 697 623,0 | - |
| 2022 | 867 683,5 | 867 683,5 | - |
| 2023 | 866 548,9 | 866 548,9 | - |
| 2024 | 866 548,9 | 866 548,9 | - |
| Барлыгы | 15 415 648,26 | 15 305 411,76 | 110 236,5 |

*Шул исәптән 11 328,6 мең сумы – Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру өчен 2017 елда алынган акчаның үзләштерелми калган, 2018 елда үзләштерелгән өлеше.

**Шул исәптән 18 432,0 мең сумы – Ярдәмче программа чараларын тормышка ашыру өчен 2018 елда алынган акчаның үзләштерелми калган, 2019 елда үзләштерергә планлаштырыла торган өлеше»;

1 нче Ярдәмче программага теркәлгән 1 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә;

1 нче Ярдәмче программага теркәлгән 2 нче кушымтаны (карарга теркәлә) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасында дәүләт икътисадый сәясәтен камилләштерү» ярдәмче программасына
2 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 11 сентябрь, 817 нче карары редакциясендә)

«2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасында
дәүләт икътисадый сәясәтен камилләштерү» ярдәмче программасын
максатчан финанслауны таләп итми торган оештыру-хокукый характердагы
чаралар

| Төп чаралар исеме | Үтәүчеләр | Төп чараларны үтәү вакытлары |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Максат исеме: Дәүләт идарәсенең нәтиҗәлелеген күтәрү, халыкның Татарстан Республикасы иҗтимагый-сәяси тормышында активлыгын арттыру, инновация эшчәнлеген һәм сәнәгать җитештерүен үстерү өчен шартлар тудыру | | |
| Бурыч исеме: Башкарма хакимият органнары тарафыннан Тататарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын һәм һәркем файдалана алырлык булуын арттыру | | |
| Җайга сала торган йогынтыны бәяләү мәсьәләләре буенча Тататарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары хезмәткәрләрен укыту | ТР ИМ*, ТР ДХБО, ЮИМ ИТУ (килешү буенча) | 2014 – 2016 еллар |
| Гражданнар, бизнес-берләшмәләр вәкилләре арасында дәүләт хезмәтләреннән һәм муниципаль хезмәтләрдән (шул исәптән рөхсәт бирү вәкаләтләренә бәйле булган хезмәтләрдән) файдалану канәгатьлелеге мәсьәләсе буенча социологик тикшеренүләр үткәрү | ТР СИМК, ТР ИМ | 2014 – 2018 еллар |
| Артык процедураларны билгеләү өчен рөхсәт бирү вәкаләтләренә бәйле булган дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтү процессларын | ТР ДХБО, ТР ҖҮО (килешү буенча) | 2014 – 2024 еллар |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| анализлау | | |
| Норматив хокукый актлар проектларының һәм гамәлдәге норматив хокукый актларның җайга сала торган йогынтысын бәяләү механизмын кулланышка кертү | ТР ИМ, ТР ДХБО | 2014 – 2024 еллар |
| Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү вакытларын оптимальләштерү, хезмәтләрдән файдалану һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәсеннән файдалану өчен хакимият органына документлар тапшыру өчен чиратта көтү вакытларын киметү буенча оештыру, норматив һәм методик чаралар күрү буенча чаралар планнарын эшләү | ТР ДХБО, ТР ҖҮО (килешү буенча) | 2014 – 2018 еллар |
| «Бер тәрәзә» принцибы буенча, шул исәптән Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр базасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру | «КФҮ» ДБУ, ТР ДХБО, ФБХОТО (килешү буенча), ТР ҖҮО (килешү буенча) | 2014 – 2018 еллар |
| Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең сыйфатын һәм алардан һәркем файдалана алу мөмкинлеген мониторинглау | ТР ИМ, ТР МһЭМ (мәгълүмат-анализ системасын төзү), ТР ДХБО | 2014 – 2021 еллар |
| Бурыч исеме: Татарстан Республикасының территориаль иҗтимагый үзидарәсе системасын үстерү | | |
| Халыкны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җәлеп итү | ТР ҖҮО (килешү буенча) | 2014 – 2024 еллар |

* Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге:

«КФҮ» ДБУ – «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе;

ТР ДХБО – Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары;

ТР СИМК – Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты;

ТР ИМ – Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы;

ТР МһЭМ – Татарстан Республикасы Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы;

ЮИМ ИТУ – «Югары икътисад мәктәбе» илкүләм тикшеренү университеты;

ТР ҖҮО – Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары;

ФБХОТО – федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары.»;

«2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган оешмаларга ярдәм күрсәтү» ярдәмче программасында (алга таба – 2 нче ярдәмче программа):

исемендә «2014 – 2021 елларга» сүзләрен «2014 – 2024 елларга» сүзләренә алыштырырга;

2 нче ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программаның исеме» юлында «2014 – 2021 елларга» сүзләрен «2014 – 2024 елларга» сүзләренә алыштырырга;

«Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2014 – 2024 еллар. Тормышка ашыру этапларына бүленми»; |

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Ярдәмче программаны финанслау күләмнәре | Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 3 252 142,67 мең сум тәшкил итә, шул исәптән Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 2 613 579,8 мең сум, федераль бюджет акчасы исәбеннән – 42 194,0 мең сум, җирле бюджетлар акчасы исәбеннән – 8 618,87 мең сум һәм бюджеттан тыш чыганаклар акчасы исәбеннән – 587 750,0 мең сум: |

| Ел | Акча күләме, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Татарстан Республикасы бюджетыннан | җирле бюджетлардан | бюджеттан тыш чыганаклардан | федераль бюджеттан |
| 2014 | 191 420,0 | 23 841,0 | 100,0 | 156 350,0 |
| 2015 | 207 758,8 | 18 353,0 | 150,0 | 146 700,0 |
| 2016 | 215 120,3 | - | 472,5 | 146 700,0 |
| 2017 | 238 782,3 | - | 1 499,3 | 15 000,0 |
| 2018 | 288 004,0 | - | 1 901,57 | 16 000,0 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 2019 | 301 881,9 | - | 1 328,0 | 17 000,0 |
| | 2020 | 234 122,5 | - | 747,5 | 18 000,0 |
| | 2021 | 234 122,5 | - | 605,0 | 18 000,0 |
| | 2022 | 234 122,5 | - | 605,0 | 18 000,0 |
| | 2023 | 234 122,5 | - | 605,0 | 18 000,0 |
| | 2024 | 234 122,5 | - | 605,0 | 18 000,0 |
| | Барлыгы | 2 613 579,8 | 42 194,0 | 8 618,87 | 587 750,0 |
| | Искәрмә: финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга ел саен, чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштыруны исәпкә алып, төзәтмәләр кертелергә тиеш»; | | | | |

«Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары)» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) | Ярдәмче программаны тулы күләмдә тормышка ашыру 2024 ел ахырына түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән финанс ярдәме күрсәтелгән социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар санын кимендә 200 берәмлеккә кадәр арттыруга;<br>Татарстан Республикасы территориясендә бер ел эчендә теркәлгән коммерциячел булмаган оешмалар санын 280 берәмлеккә кадәр арттыруга»; |

«Ярдәмче программаның индикаторлары» таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ярдәмче программаның индикаторлары

| «Соңгы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге | Индикаторларның мәгънәләре | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 2013 ел (база) | 2014 ел | 2015 ел | 2016 ел | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
| Ярдәм күрсәтелгән социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар саны, берәмлек | 120 | 204 | 202 | 171 | 315 | 367 | кимендә 180 | кимендә 200 | кимендә 200 | кимендә 200 | кимендә 200 | кимендә 200 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
